МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

17.10.2016 № 433

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы аппаратының һәм территориаль органнарының административ хокук бозулар турында протоколларны төзү вәкаләте булган вазифалы шәхесләр исемлеген раслау турында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының бүлек 10 статья 8.1 һәм “Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының сораулары” 30.12.2004 № 614 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турында кагыйдәнамәгә туры китереп, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы аппаратының һәм территориаль органнарының административ хокук бозулар турында протоколларны төзү вәкаләте булган вазифалы шәхесләр исемлеген расларга.

2. “Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы үзәк аппаратының, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы территориаль органнарының административ хокук бозулар турында протоколларны төзү вәкаләте булган вазифалы шәхесләр исемлеген раслау турында” 10.02.2010 № 68, “Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы үзәк аппаратының, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы территориаль органнарының административ хокук бозулар турында протоколларны төзү вәкаләте булган вазифалы шәхесләр исемлеген раслау турында” 10.02.2010 № 68 Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгына үзгәрешләрне кертү турында” 11.02.2012 № 235 Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы боерыклары көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының хокук белән тәэмин итү бүлеге башлыгы С.В.

Халиловка биредәге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәү һәм аннары аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми хакыйкый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рус һәм татар телендә урнаштыру буенча эшне оештырырга.

4. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының эшләре белән идарә итүчесе А.В. Молевка Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Татарстан Республикасы ГТХМ субпорталында Административ регламентны урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Биредәге боерыкны вазифалы шәхесләргә җибәрү исемлегенә туры китереп җиткерергә.

6. Биредәге боерыкны башкару контролен Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары Н.В. Суржкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

17.10.2016 г. № 433
Татарстан Республикасы
Гражданнар оборонасы эшләре
һәм гадәттән тыш хәлләр
министрлыгы боерыгы
белән расланган

## Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы аппаратының һәм территориаль органнарының административ хокук бозулар турында протоколларны төзү вәкаләте булган вазифалы шәхесләр исемлеге

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының (алга таба – Кодекс) бүлек 10 статья 8.1 туры китереп, Кодексның 3.10 статьясы белән алдан исәпкә алынган административ хокук бозулар турында протоколларны төзергә Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы аппаратының һәм территориаль органнарының (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ) түбәндәге вазифалы шәхесләре хаклы:

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры, аның урынбасарлары;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтү бүлегенең башлыгы, башлыгы урынбасары, белгечләре;

шәһәр округлары һәм муниципаль районнар буенча Татарстан Республикасы ГТХМ идарәләренең (бүлекләренең) башлыклары, Татарстан Республикасы ГТХМ гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтне башкару бүлегенең туры килә торган муниципаль районнар буенча җитәкче киңәшчеләре (җитәкче консультантлар, 1 разряд өлкән белгечләре).